| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

03.08.2026 Казан ш. 2341-р

Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре, Тукай, Мамадыш, Түбән Кама, Актаныш муниципаль районнары территориясендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклау зоналарын билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль законның 32 ст., Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында», 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Татавтодор» АҖ мөрәҗәгатьләре нигезендә, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ (21.07.2026 № 01А-04/1779, от 22.07.2026 № 01А-04/1781, № 01А-04/1783, № 01А-04/1784, № 01А-04/1785) хатын истә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә урнашкан, кадастр номеры 16:26:550201:1225 булган газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын («Татавтодор» АҖның Мамадыш филиалының җитештерү базасын газ белән тәэмин итү) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чиге урнашу урынының текст һәм график тасвирламаларындагы белешмәләргә ярашлы рәвештә, гомуми мәйданы 1791 кв.м һәм озынлыгы 384 м булган территория рәвешендә билгеләргә

(бастырылырга тиеш түгел).

2. Татарстан Республикасы Чаллы шәһәре Тукай муниципаль районы (өлешчә) территориясендә урнашкан 16:00:000000:68838 кадастр номерлы газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын («Татавтодор» АҖнең Чаллы филиалы җитештерү базасына кадәр югары басымлы газүткәргечне техник яктан яңадан коралландыру) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чиге урнашу урынының текст һәм график тасвирламаларындагы белешмәләргә, газ бүлү челтәрләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегенә ярашлы рәвештә гомуми мәйданы 2499 +/- 17 кв.м, озынлыгы 623 м булган территория рәвешендә билгеләргә (бастырылырга тиеш түгел).

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан 16:30:090703:713 кадастр номерлы газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын («Татавтодор» АҖнең җитештерү базасын газ белән тәэмин итү өлешендә О.П.О. техник яктан яңадан коралландырырга Түбән Кама муниципаль районы, Шереметьевка ав., Жуков ур., 19) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чиге урнашу урынының текст һәм график тасвирламаларындагы белешмәләргә, чикнең характерлы нокталары координаталары исемлегенә ярашлы рәвештә гомуми мәйданы 764 кв.м һәм озынлыгы 114 м булган территория рәвешендә урнаштырырга (бастырылырга тиеш түгел).

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан, кадастр номеры 16:30:011601:235 булган газ бүлү челтәре объектының саклау зонасын («Татавтодор» АҖнең Түбән Кама филиалының җитештерү базасын газ белән тәэмин итү, Түбән Кама ш., ТР АБЗ Котловкасы, югары басымлы газүткәргеч) территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чиге урнашу урынының текст һәм график тасвирламаларындагы белешмәләргә, чикнең характерлы нокталары координаталары исемлегенә ярашлы рәвештә, гомуми мәйданы 123 кв.м һәм озынлыгы 30 м булган территория рәвешендә, рәвешендә урнаштырырга (бастырылырга тиеш түгел).

5. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә урнашкан 16:04:010108:392 кадастр номерлы газ бүлү челтәре объектының (югары басымлы тышкы газүткәргеч) саклау зонасын территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона чиге урнашу урынының текст һәм график тасвирламаларындагы белешмәләргә, чикнең характерлы нокталары координаталары исемлегенә ярашлы рәвештә гомуми мәйданы 58 кв.м һәм озынлыгы 12 м булган территория рәвешендә билгеләргә

(бастырылырга тиеш түгел).

6. Өлешчә яки тулысынча газүткәргечнең саклау зонасына туры килгән әлеге карарның 1 нче пунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр в.б.** **А.И.Галиев**